## ***“Бибинур ул – мин үзем”***

*“Гыйбрәтләрне мисалга китергәндә*
*Аллаһы Тәгаләнең кодрәтле*
*яхшы сүзен искәрмәдеңмени?*
*Яхшы сүз – таза агач кеби ул,*
*тамыры нык, ә ботаклары күккә ашкан!”*
*“Ибраһим”сурәсе, 29 аять*

Аяз Гыйләҗев... Татар кешесе генә түгел, татар халкына мөнәсәбәте, мәхәббәте булган һәркем бу исемне үзгә бер горурлык, җитдилек, шул ук вакытта тирән моң белән кабатлый. “Милләтнең иң зур байлыгы – хәтер”, – ди XX-XXI гасырлар чиге татар әдәби-мәдәни мохитенең йөзен билгеләгән әдип А.Гыйләҗев. Кальбендә татар моңы булган инсан әдипкә җавап бирә: “Синең язмыш – халык язмышы, әсәрләрең – милләт хәтере. Мәңгелек хәтер”.

Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районындагы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә туган. “Тәңремә рәхмәтлемен: ул мине туганда ук шигъри күңелле иткән,” – дип яза әдип “Үзем турында үзем” истәлекләренең “Балачак сукмаклары” исемле бүлегендә: “Минем әтием тумышы белән Сарман кешесе, әнием Мөгаттәрә дә шул төбәк кызы, Сарманга терәлеп үк торган Югары Әхмәт авылында туып үскән. Әтине эшкә Чукмарлы авылына җибәрәләр, әни бер-бер артлы өч малай табып өйдә утыра.  Яшь мөгаллим дип, әтине район читендәге Югары Баграж авылына җибәргәннән соң, безнең гаилә Багражда калган. Әти урта мәктәптә химия-биология укыта, иртә-кич бакчада казынырга бик ярата иде. Метри елгасы ярында яшелчә бакчасы ясады. Яфракларыннан татлы ис таратып утыручы юаш карлыган куаклары шунда тезелде. Кыяр, кишер, чөгендер, помидор янәшәсендә кавын-карбызлар тәгәрәп үсте. Әнием оста “җөйче” иде. Безнең авылда балалар бакчасы ачкач, әнине тәрбияче иттеләр. Минем балачагым, яшьлегем әнә шул авылда – юмарт күңелле, кунакчыл,

гади, үтә кешелекле, риясыз-хәйләсез керәшеннәр арасында үтте. Олысы-кечесе безне хөрмәт итә иде”.

“Халык язмышын бербөтен итеп күрә алу сәләте – табигать тарафыннан бик сирәк кешеләргә эләккән бүләк” – дип яза әдип. Аяз Гыйләҗев тормышы – ХХ гасырда яшәгән татар язмышы хроникасы ул. “Йәгез, бер дога” исемле роман-хатирәсенә күз салыйк: “Әтием – Сарман тумасы, иң фәкыйрь “Ак ыштаннар мәхәлләсенең” имамы, 30 нчы еллар башында Алабуга төрмәсендә үтерелгән Сәхәбетдин хәзрәт улы Мирсәет – Югары Баграж дигән авылга бара да төпләнеп кала. Нигә туган төягеннән ерак-тарак, чит-ят керәшеннәр арасында калырга булганын мин соңгы елларда гына аңладым. Мулла малае булуыннан курыккандыр, ахрысы! Намуслы, эчкерсез, сабыйлык матурлыгы бер чакта да уңып бетми торган керәшеннәр яшь укытучыны зурлап каршылаганнар. Күрә әти: монда гадел, тырыш халык яши. Кулакларны куганда да Югары авыллар үз араларыннан таза тормышлы крестьяннарны читкә сөрергә ирек бирмәгәннәр. Иң эшлекле, таза тормышлы кешеләрнең йорт-җирләрен алып мәктәп салганнар, авыл советы, колхоз идарәсе төзегәннәр... Кулак хуҗаларны үз ихаталарында калдырганнар, я таш амбарга, я мунчага күчергәннәр. Югары Баграж тирә-якта атаклы, төзек һәм нык авыл булган. 30 нчы елларда ШКМ (Яшь коммунистлар мәктәбе) ачканнар, аннары урта мәктәп. ... Баграж – сугыш алды елларының бер мәдәни үзәге иде. Мәктәптәге әдәбият түгәрәгенә генә 30-40 кеше даими йөри, күпләр шигырь яза... Кыскасы, Югары авыл үзе бер дәүләт булып яши иде”.

Өченче класста кечкенә Аяз беренче шигырен яза: “Чыгарган беренче такмагым – шигъри юлларым хәтердә калмаган, соңгы юлы гына исемдә...” Дүртенче класстан шигырь-поэмалар яза башлап, бишенчедә “Ул үскәндә” повестен “әмәлләргә тотына”, күп санлы нәни пьесалар яза. ... Соңрак бөек татар язучысы, драматург Аяз Гыйләҗев язганнарын пөхтәләп, кадерләп аерым киштәләрдә саклаячак, мирас итеп сөекле тормыш иптәше мөгаллимә Нәкыя ханыма, уллары – татарның тарихчы галиме, академик, Казан (Идел

буе) федераль университетының татар филологиясе, тарихы факультеты деканы Искәндәр Гыйләҗевка, татарны дөньякүләм таныту буенча күп гамәлләр кылучы драматург Мансур Гыйләҗевка, табиб, эшмәкәр Рәшат Гыйләҗевка калдырачак.

... Роман-хатирәдән юллар: “Соңгы очрашуларның берсендә “Сез татар халкының язмышын бик иртә аңлый башлагансыз. Моңа ни сәбәп иде?” – дип сорадылар. Уйландым һәм: “Мөгаен, мин шаһит булган ачлыктыр!” – дип җавап бирдем”. “Әле дәүләт оешмаларының сатлык икәнен дә, крестьянны кычкыртып талавын да күреп-аңлап бетерә алмаган” яшьтәге Аяз “көндәлек гаделсезлек – ачлык белән һәрдаим күзгә-күз очраша”. “Ачлык мине язучы ясады, дисәм дә ялган булмас” – дип яза соңрак Аяз Гыйләҗев хатирәләрендә һәм күпсанлы хикәяләрендә, “Өч аршын җир”, “Язгы кәрваннар” һ.б. повестьларында шыксыз, ач-ялангач, рәхимсез чорның әдәби сурәтен тудыра.

Кечкенә Аяз өлкән класс укучыларының сәяси әңгәмәләрендә катнаша, “яшьтән үк җитди, сүзнең кадерен югалтмаска иялэнгән, урысчаны су кебек эчкән” Хәбир Зәйнуллинны аерып ихтирам итә: “Сүз, бәхәсләр асылда илдәге гаделсезлекләр турында бара иде – авыл кешеләре ач, фәкыйрьләр һаман бөлә бара, өй саен дүрт-биш бала, күбесе мәктәпкә йөри алмый... Инде укыган өчен дә салым түләргә кирәк. Сүздән сүз чыгып, Хәбир егетләре кайбер адәмнәрнең авыллардан кинәт кенә югалуларына хәйран калалар иде... Иң гаҗәбе шул: егетләр бөтенесе бер нәрсәгә ышаналар – юлбашчыбыз Сталин бу хәлләрне белми икән. Болар һәммәсе дә минем яшьтән алган сәяси сабакларым иде”. ... Соңрак, Сталин төрмәләрендә, ул бик күп үзе кебек нахакка рәнҗетелгән зыялылар, гади халык белән сәяси әңгәмәләр корыр, аларны һәр иҗат җимешенә – дистәләгән повесть-романнарына, пьесаларына, публицистик язмаларына, каләмдәшләренә, якыннарына юллаган күпсанлы хатларына теркәп калдырыр.

“Нигә без татар халкының кискен мизгелләрендә ни кичергәнен әдәбиятыбызда беркетеп үтмибез микән?” – дип сыкранган татар әдибе Аяз

Гыйләҗев XX гасырның 60 нчы елларында совет чоры татар әдәбиятында тәнкыйди дискурсны яңадан калкыта. Билгеле булганча, XX-XXI гасырлар чиге дөнья әдәбиятында тәнкыйди дискурсның активлашуы күзәтелә. Бүгенге авангард әдәбият поэтикасында тәнкыйди дискурсның референт компетенциясе өстенлекле. Татар әдәбияты галиме, академик Д.Ф.Заһидуллина фикеренчә, гасырлар чиге әдәбияты белән 60 нчы еллар әдәбияты арасында бу яктан күпер вазифасын А.Гыйләҗевның тәнкыйди характерлы әсәрләре ( “Балта кем кулында?”, “Өч аршын җир”, “Әтәч менгән читәнгә”) үти. Аның повестьларында җәмгыятькә тәнкыйди караш герой дискурсы буларак тәкъдим ителә.

... Роман-хатирәдән юллар: “1944 нчедә Югары Баграж урта мәктәбен яптылар, унынчыга мин Сарман мәктәбенә бардым. 44 тә Казан университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылды. Алдагы бәхетле көннәргә юл бары тик университет аша үтә!” Ләкин хөр фикерле, кыю яшүсмер Аяз “Рәсәй тормышын иң гадел, иң гүзәл тормыш үрнәге дип ышандырырга тырышкан укытучыларның” өйрәтмәләрен тыңлар хәлдә түгел: “университет мин ашкынып-газапланып көткәннәрне бирмәде, үземне яшь чагымнан борчыган сорауларга җавап табу түгел, сорауларым тирәнәйделәр, ишәйделәр, авырая бардылар”. ...Университет мөгаллимнәрен гаепләмичә, киресенчә, аклап уку йортыннан киткән Аяз Гыйләҗев соңрак тормыш куйган сорауларга катгый җавап бирә: “Үзеңнең зурлыгыңны, халыкның бөеклеген бары тик эш белән, акыл белән, мәдәният-сәнгать әсәрләре белән генә күрсәтеп була”. Татар әдипләре өчен иң югары бүләк – Г.Тукай бүләге (1983), Рәсәй күләмендәге А.М.Горький исемендәге Дәүләт бүләге (1987) иясе, халык язучысы (1993) А.Гыйләҗев “әдәбиятның нигезендә миллилек ята” дип раслауны иҗат концепциясе итә.

... 18 яшьлек егетнең “саф күңеле ил тормышын киңрәк күрергә омтыла”, язмыш аны Әстерханга алып килә. Әстерхан “сәфәреннән” “Сталин режимының тоташ гаделсезлеген” тәмам төшенеп Багражга кайтканнан соң, “хаклыкны зарыгып төрле якларга ташланган” шигъри күңелле егет

Ф.Достоевскийның “Җинаять һәм җәза” романын “онытылып-уянып укый”: “Достоевскийның “Газап һәм күз яшьләре дә тормышының үзе бит”, дип раславы миңа алдагы көннәремә иман булды”. Аяз тынгысыз җанына урын таба алмый газаплана, “туганнары буйлап сәфәр чыгып китә, шигырьләр яза”. ...Соңрак 1974 елда “Язгы кәрваннар” повестенда “бәрәңге галиҗанапләре” эзләп юлга чыккан ач балачагы тасвиры туа. Бу повесть А.Гыйләҗевны рус әдәбиятының классиклары дөньякүләм билгеле А.Солженицын, В.Распутин, В.Шукшин, В.Астафьев һ.б.лар рәтендәге авыл реализмы агымы вәкиле итеп таныта. Авыл прозасы (крестьян реализмы) – 1970 нче еллар чигендә СССР дип аталган территориядә яшәүче халыклар әдәбиятында социалистик реализмга сыешмыйча барлыкка килгән агым. Неорелизмның беренче агымы милли һәм әхлакый кыйммәтләргә ия булган авыл кешесен, җирдә эшләүчене сурәтләгәнгә авыл реализмы дигән термин белән атала. А.Солженицын бу агым вәкилләрен “әхлакчылар” дип атый.

... Булачак язучы 1947 елда “кыршалган бригадир букчасын иңенә салып, кирза итеге белән яңа сукмаклар салып”, Зәй районында комсомол оешмасында эшли башлый: “Авыл тезләнгән, хәлсез. “Комсомолдан” дигәч, сиңа тиле кешегә баккандай карап торалар. Нинди комсомол, кемгә хаҗәт ул?.. Нигә без балачактан бер-беребезне алдарга һәм алданырга өйрәтәбез?”

“Ул елларда мин байтак хикәяләр яздым, шигырьләр сызгаладым. Язганнарымны гәзит-журналларга тәкъдим итмәдем. Мин ачылып та җитмәдем, йомылырга да уйламадым”. 1948 елның көзендә А.Гыйләҗев яңадан университетка керергә тәвәккәлли. Шул ук елны беренче тапкыр аның “Ян учагым, ян!” хикәясе дөнья күрә.

1947 елны район укытучыларының еллык киңәшмәсендә трибунадан хаклыкны якларга омтылып: “Мәктәпләрнең хәле мөшкел, укытучылар сөрсеп беткән, күбесе күгәрек белән капланган”, – дигән сүзләре өчен А.Гыйләҗевны МГБ га чакырталар. Университетта әдәбият түгәрәгендә хикәяләр уку егетне “советка каршы” кеше буларак таныта, иптәшләре читләшә башлый. “Ленинец” гәзитенең 1949 елгы 8 апрель санында

урнаштырылган (№12/314) “На неправильных позициях” (“Ялгыш юлда”) исемле мәкалә әдипнең бер хикәясенә бәя бирүне генә күздә тотмый, Аяз Гыйләҗевның язучы буларак та, харизма-шәхес буларак та язмышын билгели.

“Атаклы 1948-49 еллар бу! Илдә кешеләр аңын чираттагы “чистарту” бара... Шушы бер мәкалә үзе генә дә мине Черек күлгә илтеп ябарга азык була иде”. 1950 елның 22 мартында 58 нче номерлы маддә буенча (“контрреволюцион агитация һәм пропаганда өчен”) А.Гыйләҗев кулга алына. Җизказган, Киңгир, Балхаш, Актас, Волынка – лагерьлар, бакыр рудниклары, шахталар. ... Соңрак, хаклыкны язу мөмкинлеге тугач, А.Гыйләҗев “Йәгез, бер дога!” романында “шөкер кылачак”: “Черек күлдә, тимер ишекләр артында саклана торган “Тикшерү дело”сында шактый кызыклы фикерләрем, беркетмәләргә сыланган сүзләрем калган минем... Бүген йөзем ачык: кыю вә хак фикерләр әйтә алганмын ич!” Әдип татарлар гына түгел, “большевизм камаган бәхетсезләр” – “урыслар, яһүдләр, японнар, немецлар, балкарлар”га дога кылачак: “Мин сезгә, һәрбарчагызга искиткеч рәхмәтлемен: минем рухым бөтенлеген сез саклап калдыгыз, җанымның Аллаһы Тәгалә биргән бөтенлеген ваттырмадыгыз”.

“1955 елның көзендә мин илгә кайттым. 1956 ның февралендә зур мәшәкатьләр чигеп университетның икенче курсында укый башладым. Хикәяләр, пьесалар язам. 1957 ел, 2 марттан “Чаян” журналында эшли башладым” – дип дәвам итә ул истәлекләрен.

Татар язучысы Аяз Гыйләҗевның әдәби иҗаты, публицистикасының концептуаль нигезе нидән гыйбарәт дип сорасалар, бер дә икеләнмичә, әдипнең үз сүзләре белән җавап кайтару дөрес булыр: “Әгәр язучы ***татар халкының төбенә төшә алмаган икән, аның яшәеш рәвеше белән рухланмаган икән, татар халкына мәхәббәте юк икән*** – ул инде татар әдәбияты түгел”. Шул ук вакытта “Үги ана яфраклары” (1961) хикәясенең герое Галимҗан турында әйткәндә, әдип үз идеалын түбәндәгечә сыйфатлый: “Күккә һәм җиргә карап, төрле уйлар уйлана белә торган, мәхәббәтнең

изгелеген, олылыгын, ***кешенең мәхәббәтен кабатланмас горурлыкта булырга тиешлеген*** аңлаган тәрбияле, нечкә күңелле кеше... Ул матурлыкны кабул итә белә, үзе дә аны тудырырга омтыла, дөнья әдәбиятын – Экзюпериларны, Хемингуэйларны укый, төньякның гүзәл сихерчесе Григны бөек Сәйдәшне сөйгән кебек үк сөя, әмма барлыгы, бөтен яшәеше белән шушы җирдә, үзебезнең җирдә яшәүче бай рухлы егет”. Язучының улы Искәндәр Гыйләҗев болай искә ала: “Әти бик күп укый иде. Аның кабинетында хәзер дә Хемингуэй, Сент-Экзюпери, Селинджер, Фолкнер, Генрик Ибсен, Тургенев, Достоевский, Есенин китаплары саклана”. Татарның диңгезче-маринист әдибе Миргазиян Юныс аның “Урамнар артында яшел болын” (1969) романын дөнья классигы Эрнест Хемингуэйның иң көчле, тирән хисләрне гәүдәләндергән “Елга артында, агачлар күләгәсендә” әсәре белән чагыштыра, “Язгы кәрваннар”ны (1974) Джек Лондонның “Яшәү мәхәббәте”, Э.Хемингуэйның “Карт һәм диңгез” хикәяләре белән бер рәткә куя.  М.Юныс: “Аяз Гыйләҗев үзе Джек Лондонның “Мексикалы” хикәясенең герое Фелипе Риверага охшаган: кырыс, максималист, ялганга каршы аяусыз, үз кыйбласына тугры кеше,” – дип тә белдерә.

1960 нчы елларда соцреализмда катып калган татар әдәби-мәдәни мохите киң карашлы, дөнья мәдәниятеннән хәдәрдар, татар әдәбиятының Г.Тукай, Ф.Әмирханнары, Ш.Камалларына мөкиббән үзфикерле әдипне кабул итәргә әзер идеме соң?  Татар прозасында яңа үсеш баскычы булган, аны рус әдәбияты, дөнья мәдәнияте югарылыгына борган “Өч аршын җир” (1963) повестеның басылу тарихы турында А.Гыйләҗев болай сөйли: “Повестем “Совет әдәбияты” журналында дөнья күргәч, аны чын тәнкыйть утына тоттылар.Журналның баш мөхәррире Газиз Мөхәммәтшинны хәтта, советка каршы әсәр бастыргансың, дип, көн-төн обкомга чакырттылар. Ә инде повестьны китап итеп бастырып чыгару? Шушы вакыйгадан соң нәшрият аны якын да китермәде. Әсәр Мәскәүдә Искәндәр Гыйззәтуллин тәрҗемәсендә “Дружба народов” журналында рус телендә басылып чыкты,

елның иң яхшы әсәре буларак, махсус премиягә лаек булды. Хәтта ул Мәскәүдә аерым китап булып тиз генә нәшер ителде. Шуннан соң 15 еллар үткәч кенә әсәрем җыентыгыма кертелде".

Гаделлек сакчысы А.Гыйләҗев, үз сүзләре белән әйткәндә, "бирешә торганнардан түгел". Әдәбият галиме, чордашы, каләмдәше, язучы, академик Т.Н.Галиуллин "Аязның повестьсыз калган елы булмады", – дип яза. Бер-бер артлы язылган һәм басылган "Дүртәү" (1958), "Берәү" (1958), "Качак" (1959), "Зәй энҗеләре" (1963) повестьларында А.Гыйләҗев әхлакый кыйммәтләрне югары күтәрә, иҗтимагый кануннарны тәнкыйтьли. "Урталыкта" (1969) повесте, әдипнең үз сүзләре белән әйткәндә, "кеше гомеренең кап уртасында вакытның тукталган мизгелен" тергезә. Шәһәр темасын гәүдәләндергән "Күзгә-күз" (1975), "Мең чакрым юл" (1978) әсәрләрендә автор мәдәни, интеллектуаль традицияләр хакында яза. "Әтәч менгән читәнгә" (1979-1980) повесте татар әдәбиятында герой дискурсы үрнәге: Хәйретдин агай образы аша белдерелгән тәнкыйди караш автор концепциясе кебек формалаштырыла. Тирән психологизмга корылган "Яра" (1981-1988) повесте – әдипнең иң яраткан әсәрләреннән. "Балта кем кулында?" (1988-1989), "Йәгез, бер дога!" романнары милли прозада тоталитар җәмгыятьне гаепләү акты булып яңгырый. Башка авторлар белән берлектә язылган "Алтынчы августка кадәр" (А.Литвин белән берлектә) роман-хроникасы, "Шамил Усманов" (А.Яхин белән берлектә) драмасы әдәби алымнар байлыгы ягыннан үзенчәлекле.

Драматургиясе хакында А.Гыйләҗев үзе болай ди: "30 дан артык пьеса язсам да, мин драматург була алмадым. Мин сәхнәне тормышны өйрәнә торган университет дип аңладым. Аны халыкны тәрбияләү чарасы итеп кулланырга алындым. Шуңа күрә Чехов, Шоу кебек акыллы драматургларны үземә остаз итеп алдым". 1960-70 елларда язылган һәм куелган "Җиз кыңгырау", "Киек каз юлы", "Көзге ачы җилләрдә", "Җиргә тапшырылган серләр", "Хушыгыз, тургайлар", "Әгәр бик сагынсаң..." һ.б. драма

әсәрләрендә автор прозада билгеләгән кыйбласына тугры кала, әхлакый проблемаларга басым ясый.

Татар әдибе  дөнья классигы А.де Сент-Экзюпериның мәгълум гыйбарәсенә (“Мине язганнарымнан эзләгез”)  тугры кала.  А.Гыйләҗев
үзенең әлегә басылмаган 30 томлык мирасы барлыгы турында әйтә. Язучы иҗатын тирән өйрәнгән галим академик Т.Н.Галиуллин  әдипне “киләчәк кешесе” дип атый һәм ялгышмый.

***“Җомга көн, кич белән...” (март-октябрь, 1979) повесте*** татар әдәбияты тарихында гына түгел, дөнья мәдәнияте күгендә  Аяз Гыйләҗевның исемен йолдыз итеп балкыта. Т.Галиуллин болай ди: “Башка әсәр язмаса да, “Җомга көн, кич белән...” повесте белән генә дә А.Гыйләҗев татар әдәбияты тарихында калыр иде”. ““Җомга көн, кич белән...”  повестен укый башлау белән Лев Толстойны чиктән тыш дулкынландырган проблемага кереп китәсең. Бу дөньяда үз бәхетең өчен тырышканда түгел, башка кешеләрне бәхетле итәргә тырышканда бәхетле булып була, – ди М.Юныс. – Төрки хатыннарның бала җанлы булуын фәнни тикшеренүләр раслый. Бу турыда XI гасырның беренче яртысында Ибне Бутлан язып калдырган”.

Парадоксаль хәл: алда әйтеп кителгән Казан университетының “Ленинец” гәзитендә А.Гыйләҗевны “Ана” хикәясе өчен битәрлиләр. Мәгълум повесте басылгач, “Бибинур ул – мин үзем”, – ди бөек татар әдибе. Кабатлап әйтик, Ана образы, чыннан да, әдипнең чиксез михнәтле, шул ук вакытта бәхетле язмышын билгели. XX йөз уртасында эшләнгән образ А.Гыйләҗевны XXI йөзнең беренче унъеллыгын йомгаклаганда дөнья мәдәнияте аренасында таныта. Санкт-Петербург режиссеры  Юрий Феттинг әдипнең улы Мансур Гыйләҗев  эшкәткән сценарийга нигезләнеп, “Бибинур” исемле әдәби-нәфис фильм төшерә. 2010 елны Халыкара “Алтын мөнбәр” мөселман кинофестивалендә Гран-при, төп номинацияләрдә җиңүче исемен яулаган әлеге татар фильмының нигезенә әдип эшкәрткән Бибинур образының концепциясе салына. Эчтәлеге А.Гыйләҗевның “Өч аршын җир”, “Җомга көн, кич белән...” повестьларын үзгәртеп эшләнә. Фильм “Евразия”

Халыкара кинофестивалендә, Германиянең Котбус шәһәрендә оештырылган XX Көнчыгыш Европа кинофестивалендә катнаша. Санкт-Петербургтагы фестивальдә Көмеш Грифон ала, Мәскәүдә Хакимиятнең югары бүләгенә лаек була. Бу фильмның инглиз режиссеры Джон Ирвин җитәкләячәк 32 нче Мәскәү Халыкара кинофестивалендә катнашачагы билгеле.

"Бибинур" фильмының иң көчле урыны дип Ю.Феттинг азан күренешен атый: "Азан кешеләрне үз асылларына кайтырга чакыра, Илаһияткә эндәшергә өнди". Рус режиссеры дөнья мәдәниятенә тәкъдим иткән үзәк мотив А.Гыйләҗев повестен каймалап ала. Повестьны кабул итәргә автор укучыны исемгә чыгарылган мәгънә белән көйли. Күкләрдә бәйрәм ителүче, Адәм г.с. туган, җәннәткә кергән, шулай ук кыямәт көне булачак ***җомга көне*** – җыелу көне, атна дәвамында кылынган гамәлләргә хисап бирү вакыты кебек уйланылган. Татар-мөселман рухына автор шул вакытны исемгә чыгару белән үк алып керә. Повестьның исемен укуга, укучы бер мәлгә уйланып куя, әсәр текстыннан түземсезләнеп фани дөньядагы гамәлләргә бәя булып яңгырар дәрәҗәдә яңа сүз – дога көтә башлый. А.Гыйләҗев алдан ук татар рухына ***һәр татар кешесенең табигатенә салынган Илаһи көчкә үз язмышыңны тапшыру хисе*** аша эндәшә. Көн дәвамында булган хисләр бер бәйләмгә тупланган ***кичке вакыт*** – уйлану мәле. Шул рәвешле, автор дога укыгандагы халәткә – ***тын калып уйланырга*** чакыра.

Язылу-басылу көненнән башлап бу әсәргә бер татар кешесенең дә битараф калганы юк. Повесть турында меңләгән гади укучы, тәнкыйтьче, әдәбият галиме, телче язды. Әсәрне укып еламаган бер генә ир заты, хатын-кыз юк! "Бибинур ул – мин бит!" – дип әрни гасырлар буе изелеп килгән, таралган-таркалган һәр татар кешесе. Бибинурга татар-төрки җанлы – җиз самоварлы, җылы сөтле, кунак-сыйлы дөньяны югалтканга моң-зарлы һәркем соклана, Бибинурны безнең милләткә катнашы булмаган сәнгать сөюче кызгана. Димәк, ***Бибинур образы – татар җаны, аның эчке, бик тирән якты дөньясы, тирәлектә үз кирәген таба алмый сыкраган йомшак-нечкә***

***күңеле ул. Гасырлар аша кыю үтеп баручы горурлык хисе, сабырлык, ярату көче ул.***

Эпиграфларда автор укучысы белән һәркем өчен кадерле, газиз кыйммәтләр ярдәмендә сөйләшә. Беренче – авторның үз сүзләре дип тамгаланган эпиграф махсус рәвештә татар кешесе өчен ят булган Вальпараиса, Галлопогос, Титикака, Куала-Лумпур кебек атамаларны яңгырату белән башлана. Бу атамалар никадәр ят булса, “Аксыргак авылы, Ташлыяр елгасы” шулкадәр үз тоела. Билгеле, авторның ”кадерле булганга күрә шәбрәк яңгырый” дигән сүзләре белән килешми мөмкин түгел. Әдип ***татарның үзенә бәйсез яши торган тагын бер ягын – нәселне туплап торган урынга изге дип каравын ача һәм укучыдагы шул хисне кузгатып куя.***

Икенче эпиграфта автор бу хакыйкатьне Габдулла абый Юсупов сүзләре белән раслап куя. ***Татар кешесенең аң төпкелендә үзеннән өлкән кешегә ихтирам, аның сүзенә колак салу тиешлеге урнашкан.*** Автор Габдулла абый Юсупов образын “тәҗрибәле кешенең” ышанычлы сүзе буларак кертеп җибәрә, олы кеше “җылавының” сәбәбен эзләтә. Бу кешенең эчке, рухи дөньясы - *йорты* япа-ялгыз, аның күңеле башка дөнья өчен ябык - *тәрәзәләре* “томаланган”. Әбинең бу яман халәте күптәннән үзгәрешсез: “ихатада башка корылмалар күптән ишелеп беткән”. Татар һәм башкорт мифологиясендә киң таралган каен-кайгы укылышы аша автор сак кына әби язмышын милләт язмышы кебек гомумиләштерә: ***татар хәсрәтенең нигезе – аның аң төпкеленә укмашкан дәшми тору сыйфаты*** (*череп укмашкан салам)* ул. ***Шул ук вакытта аның йортының түбәсен саклаучы да шул (каен бастырма), ягъни аның рухи нигезен түземлелек кенә әрсез җил иркенә бирмичә - “коточкыч юкка чыгудан” саклап тора. Бу – караңгыда да күренә торган көн кебек ачык парадоксаль хакыйкать, ди әдип. Татар кешесенең табигатенә салынган түземлелек иҗтимагый шартларда аны бәхетсез итә, ләкин, үзе булып калырга теләсә, татар башкача була алмый.*** Татар кешесен чиксез – *серле* мәңгелеккә илтүче як – бик иртә

өзелгән өметләргә бәйле ***моң. Мәңгелек хәтерендә татар кешесенең сәҗдәгә китеп уйга чумган халәтеннән бер хис уелып кала – татар аны моң, ди. Үзен кем дип атаса да, татар каны булган кешедә шул хис үзенә бәйсез рәвештә яши, аны кабат-кабат "сәҗдәгә китеп" үз асылы турында уйланырга – "җыларга" мәҗбүр итә, ди язучы.***

Соңгы сүз татар халкының үзеннән әйттерелә. Өченче эпиграфны автор "татар халкының яраткан җыры" дип билгели.

***Моң халәте татар кешесенең даими эчке халәте, ахыр килеп, аны олы сабырлык юлына алып чыгучы хакыйкать, ди әдип***.

Бибинурны ташлап киткән, ялгыз иткән балалар – милли йөзләрен җуйган мескеннәр - бүгенге чынбарлык ди, А.Гыйләҗев XX йөз ахырында. Гомеренең соңгы елларында (2002 елның 13 мартында әдип вафат була) А.Гыйләҗев телләрен, диннәрен югалткан яңа буын турында әрнеп яза, татарча укучы табылмас, дип сызлана. Ләкин ике гасыр чигендә Бибинур образының көче мәдәниятләрне берләштерә. Бүгенге дөнья әдәби-мәдәни мохите Бибинурны яңадан "укый", укыган саен мәгънә ача. Татар халкының бөек әдибе, милләт хадиме Аяз Гыйләҗев исемен XXI йөз дөнья мәдәнияте мәңгеләштерә.

Гөлфия Гайнуллина,
Казан (Идел буе) федераль университеты доценты